ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 10.07.2015 г. Казань № 10-14/кс

***Эчергә яраклы суга, су бүлүгә һәм техник суга тарифлар билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүче һәм су агызуны башкаручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга һәм су агызуга тарифларны, билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 мартыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүче һәм су агызуны башкаручы оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисе вазифаларын башкаручу Л.П.Борисова

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
10.07.2015 № 10-14/кс

Салкын су белән тәэмин итүче һәм су агызуны башкаручы оешмалар өчен эчәргә яраклы суга, су бүлүгә һәм техник суга тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су агызуны башкаручы оешмалар, муниципаль берәмлекләр атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы) сум/куб. | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы) сум/куб.м | Техник суга тариф (әйлән-мәле су белән тәэмин итү) (бер ставкалы сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Аксубай муниципаль районы | | | |
| 1 | «Аксубаевское МПП ЖКХ» ААҖ | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 17,04 | 19,69 | |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 14,44 | 16,69 | |
| | Нижнекамск муниципаль районы | | | |
| 2 | «ТГК-16» ААҖ | | | |
| 2.1 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | | | 4,82 |
| | Балык бистәсе муниципаль районы | | | |
| 3 | «Балык бистәсе торак коммуналь сервис» ҖЧҖ** | 25,80 | 26,86 | |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә.
<**> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге